СОВЕТ ОКТЯБРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОКТЯБРЬ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

*Юрид. адрес: 423984, РТ, Муслюмовский район, с. Октябрь, ул. Молодежная, д.3а.*
*Факт. адрес: 423984, РТ, Муслюмовский район, с. Октябрь, ул. Центральная, д.33А.*
Okt.Mus@tatar.ru *тел. 8(8-5556) 3-51-26*
ИНН 1629001152, КПП 162901001, ОГРН 1021605557863, ОКАТО 92242860001

Октябрь авылы «08 » июнь 2021 г.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОКТЯБРЬ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XV УТЫРЫШЫ

**Карар№22**

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм тәртип кагыйдәләрен раслау турында» 2019 нчы елның 8 нче ноябрендәге 89 нчы номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге Советы карарына үзгәреш кертү хакында**

Гамәлдәге законга туры китерү максатында, Мөслим муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм тәртип кагыйдәләрен раслау турында» 2019 нчы елның 8 нче ноябрендәге 89 нчы номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

- 116.13 пунктны «(әмма тиешле тәртиптә төзелгән һәм дәүләт кадастр исәбенә куелган җир кишәрлекләренең милекчеләре өчен, әгәр Россия Федерациясе законнарында каралган мәҗбүри таләпләрне бозмаса, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында Карар кабул итү мөмкинлеге тулысынча юкка чыгарылырга тиеш түгел)» дигән җөмлә белән тулыландырырга.

2. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм тәртип кагыйдәләрен раслау турында» 2019 нчы елның 8 нче ноябрендәге 89 нчы номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге Советы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Октябрь авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Октябрь авыл башлыгы И.М.Ханнанов